МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 апрель 2026 ел № М 213

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Хаким (Шәһәр Советы) аппаратында гражданнар билгеләнгәндә һәм муниципаль хезмәткәрләр биләгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеге хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 һәм 8.1 статьялары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Хаким (Шәһәр Советы) аппаратында гражданнар билгеләнгәндә һәм муниципаль хезмәткәрләр биләгәндә үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген кушымтада каралганча расларга.

2. Исемлектә күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр үзләренең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар бирергә бурычлы дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинга йөкләргә.

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2026 елның 28 апрелендәге
М 213 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Хаким (Шәһәр Советы) аппаратында гражданнар билгеләнгәндә һәм муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган муниципаль хезмәт вазыйфалары
исемлеге

| № | Вазыйфаның исеме |
|---|---|
| 1. | Хаким (Шәһәр Советы) аппаратының эшләр идарәчесе |
| 2. | Хаким ярдәмчесе |
| 3. | Хаким ярдәмчесе (коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча) |
| 4. | Хаким ярдәмчесе (халык белән эшләү буенча) |
| 5. | Оештыру-аналитик һәм хокукый эшләр идарәсе башлыгы |
| 6. | Хаким (Шәһәр Советы) эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы |

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

И.А. Сәгыйдуллина